СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

## Шушмабаш авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

**от 14 июль 2026г.** **№27**

### Татарстан РеспубликасыАрча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган территория чикләрен билгеләү турында

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында" 2014 елның 02 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган, үз эченә Шушмабаш, Шекә, Носы, Сәрдәбаш, Илдус, Ишнарат, Үге-Елга авылы торак пунктларын алган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге чикләрен территория чикләре дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:
- "Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында" 2014 елның 17 декабрендәге 121 номерлы;
- "Шушмабаш авыл җирлеге Советының "Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында" 2014 елның 17 декабрендәге 121 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" 2016 елның 14 декабрендәге 38/1 номерлы;
- "Шушмабаш авыл җирлеге Советының "Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында" 2014 елның 17 декабрендәге 121 номерлы

карарына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 7 сентябрендәге 85 номерлы (2016 елның 14 декабрендәге 38.1 номеррлы үзгәрешләр белән)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы

В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012678